Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә” муниципаль берәмлеге Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

17 ноябрь 2025 ел

№ 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 08 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2025 елның 08 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 2025 елның 08 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2025 елның 08 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта, 2025 елның 09 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2025 елның 09 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 2025 елның 09 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2025 елның 09 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта, 2025 елның 15 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2025 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2025 елның 15 ноябрендә 11 сәгать 30 минутта, 2025 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2025 елның 16 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге “Сез 2026 елда Түбән Мактама ш.т.б. территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым кертү, 1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокырларны ремонтлау, вак таш җәю, юлларга асфальт салу); урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычларны алыштыру һәм сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен төзү); традицион күмү урыннарын төзекләндерү (дератизация, куакларны кисү, печән чабу) өчен түләүгә ризамы?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 7491 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 4485 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 2967 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 1518 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә” муниципаль берәмлеге Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. “Сез 2026 елда Түбән Мактама ш.т.б. территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым

кертү, (1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш) һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокырларны ремонтлау, вак таш җәю, юлларга асфальт салу); урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычларны алыштыру һәм сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен төзү); традицион күмү урыннарын төзекләндерү (дератизация, куакларны кисү, печән чабу)өчен түләүгә ризамы?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Мактама шәһәр тибындагы
бистә башлыгы В.Н. Сенин